**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА МОНАСТЫРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422392, Республика Татарстан,

Тетюшский район, с. Монастырское,

ул. Комсомольская, д.33

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОНАСТЫРСК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422392, Татарстан Республикасы,
Тәтеш районы, Монастырск авылы,
Комсомол урамы, 33

Тел. (84373)5-45-20, факс: 5-45-20, e-mail: monastyr.tetushi@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**27 .10. 2025** **№ 3**

**2026 елда гражданнарга үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлегенең Лаптевка торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Монастырское авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. карар бирәм:

1. 2025 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлегенең Лаптевка торак пунктында 2026 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча урнашкан Лаптевка авыл мәдәният йорты бинасында билгеләргә: Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Лаптевка авылы, Гагарин урамы, 4 йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлегенең Лаптевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда үзара салым кертүгә 1000,00 (бер мең) сум күләмендә ризамы сез, аерым алганда: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балаларны һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Лаптевка торак пунктында Ленин урамы буенча торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

» КАРШЫ «РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Монастырь авыл җирлеге башкарма комитетына граждannар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **А.А. Васин**